ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЧУРАКАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

423746, Чуракай авылы,
Совет ур., 69 нчы йорт.
Тел.3-44-65

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА ЧУРАКАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423746, село Чуракаево,
ул. Советская,дом 69,
Тел. 3-44-65

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№1

КАРАР
21.03.2024

Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Башлыгының «Муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибен, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеген, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибен раслау турында» 2010 елның 30 мартындагы 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Башлыгының 2010 елның 30 мартындагы 1 номерлы «Муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибен, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеген, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибен раслау турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 4.2 нче пунктта "яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматны күрсәтүне" сүзләрен, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, "белә торып тулы булмаган мәгълүматны күрсәтүне яки белә торып дөрес булмаган мәгълүматны күрсәтүне" сүзләре белән алыштырырга;

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык Р.Р.Хайдаров